| Республика Татарстан<br>Глава Верхне-Чершилинского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Югары Чыршылы авыл<br>җирлеге башлыгы |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.11. 2021г № 4

2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1. Югары Чыршылы авылы мәдәният йорты бинасы янында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын 2021 елның 19 ноябренә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә

2.Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Югары Чыршылы авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2) Югары Чыршылы авылында Сабантуй, өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

3) Югары Чыршылы авылында балалар уен мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (ком ташу);

4) Югары Чыршылы авылында артезиан скважиналары территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары, буяу сатып алу, эшләр өчен түләү);

5) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

6) Югары Чыршылы авылы зираты өчен инструментлар (генератор, отбойный молоток) сатып алу;

7) Югары Чыршылы авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар сатып алу һәм урнаштыру;

8) "Сарман" район газетасында некролог бастыру.

«ӘЙЕ «ЮК»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов